УДК 811.512.145:81’366.59:070

***Б.К. Миңнуллин***

# ХХ ГАСЫР БАШЫ ТАТАР ГАЗЕТАСЫ ТЕКСТЛАРЫНДА ТИЕШЛЕК МӘГЪНӘСЕН БЕЛДЕРӘ ТОРГАН ФОРМАЛАРНЫҢ КУЛЛАНЫШЫ ҺӘМ СЕМАНТИК-ГРАММАТИК ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

Настоящая статья посвящена комплексному анализу форм, выражающих значение долженствования в текстах татарских газет начала XX века. Цель исследования состоит в выявлении и сопоставлении форм долженствования в текстах газет «Борхане таракки», «Вакыт» и «Кояш», анализе способов выражения значения обязательности либо необходимости и прослеживании эволюции грамматических средств в старотатарском литературном языке.

Научная новизна статьи заключается в проведении комплексного сравнительного исследования форм, выражающих значение долженствования на материале публицистики начала XX века. В работе систематизированы разнообразные синтетические, аналитические и описательные конструкции, уточнено их распределение по изданиям и выявлена связь с процессами языковой вариативности и перехода к современному татарскому литературному языку. Особое внимание уделено влиянию огузских языковых элементов на старотатарский письменный язык.

Автор работы приходит к выводу, что наиболее распространенной формой долженствования во всех трех газетах является конструкция с инфинитивом на *-yrğa* и модальным словом *tiješ* ‘должен’, спрягаемая по лицам. Результаты исследования демонстрируют, что в газете «Борхане таракки» фиксируется наибольшее разнообразие синонимичных аналитических форм с модальными словами *kiräk* ‘необходимо’ и *lazem* ‘нужно’, а также использование формы *-maly*, характерной для огузских языков, тогда как в текстах газетах «Вакыт» и «Кояш» преобладают описательные формы (*-yrğa tiješ ide, -yrğa tiješ bul*), реже встречается конструкция *-maq lazem*. Установлено, что вариативность средств выражения долженствования в текстах газеты «Борхане таракки» отражает влияние традиционных общетюркских элементов и форм, проникших через османско-турецкое посредство, а также выявлен процесс постепенного перехода от использования традиционных грамматических элементов к новым формам, которые впоследствии легли в основу современного татарского литературного языка. Результаты вносят вклад в изучение истории татарского языка, тюркской морфологии и языковой вариативности в публицистическом дискурсе.

**Ключевые слова:** формы долженствования, старотатарский письменный литературный язык, татарская газета начала XX века, языковая вариативность, модальные слова, грамматическая синонимия

This article is devoted to a comprehensive analysis of the forms expressing the meaning of duty in the texts of Tatar newspapers of the early 20th century. The purpose of the study is to identify and compare the forms of obligation in the texts of the newspapers “Borkhane tarakki”, “Vakyt” and “Koyash”, to analyze the ways of expressing the meaning of obligation or necessity and to trace the evolution of grammatical means in the Old Tatar literary language.

The scientific novelty of the article is to conduct a comprehensive comparative study of the forms expressing the meaning of duty based on the material of journalism of the early 20th century. The work systematizes a variety of synthetic, analytical and descriptive constructions, clarifies their distribution by publications and reveals the connection with the processes of linguistic variability and transition to the modern Tatar literary language. Special attention is paid to the influence of the Oghuz language elements on the Old Tatar written language.

The author comes to the conclusion that the most common form of ought in all three newspapers is a construction with an infinitive in *-yrğa* and the modal word *tiješ* 'must'. The results of the study demonstrate that the newspaper "Borkhane tarakki" contains the greatest variety of synonymous analytical forms with the modal words *kiräk* 'necessary' and *lazem* 'necessary', as well as the use of the form *-maly,* char acteristic of the Oghuz languages, whereas descriptive forms prevail in the texts of the newspapers "Vakyt" and "Koyash" (*-yrğa tiješ ide, -yrğa tiješ bul*), a less common construction is *-maq lazem.* It is established that the variability of the means of expressing obligation in the texts of the newspaper "Borkhane tarakki" reflects the influence of traditional common Turkic elements and forms that penetrated through the Ottoman-Turkish medium, and the process of gradual transition from the use of traditional grammatical elements to new forms that later formed the basis of the modern Tatar literary language is revealed. The results contribute to the study of the history of the Tatar language, Turkic morphology and linguistic variability in journalistic discourse.

**Keywords:** forms of obligation, Old Tatar written literary language, Tatar newspaper of the early 20th century, linguistic variation, modal words, grammatical synonymy

Билгеле булганча, лингвистик традициядә татар теленә карата *тиешлек наклонениесе* терминын кулланганда, аерым морфологик категория түгел, ә кирәклек һәм мәҗбүрилек модальлеген белдерүнең лексик һәм грамматик чаралары комплексы белән күрсәтелә торган функциональ-семантик кыр күздә тотыла. Әлеге семантиканың төп күрсәткечләре булып *тиеш* һәм *кирәк* модаль предикативлары, шулай ук синтаксик конструкцияләр һәм мәҗбүрилек мәгънәсен тормышка ашыруның контекстуаль шартлары тора.

Бүгенге көндә тюркологиядә тиешлек наклонениесе төрки телләрнең угыз группасына хас үзенчәлекле сыйфат буларак билгеләнә [28: 211]. Аерым алганда, төрек әдәби телендә тиешлек наклонениесе хәзерге-киләчәк һәм үткән заман формаларына ия һәм *-maly* махсус грамматик күрсәткече ярдәмендә ясала [23: 244]. Хәзерге татар әдәби телендә тиешлек мәгънәсе *-асы* синтетик күрсәткече ярдәмендә белдерелергә мөмкин, ләкин, гадәттә, әлеге мәгънәне белдерү өчен *-асы иде* аналитик конструкциясе, *-ырга* инфинитивы һәм *тиеш* модаль сүзе кушылмасы, *бул-* фигыле белән ясалган тасвирлама формалар кулланыла [30: 168–169].

XX гасыр башы татар газетасында, аерым алганда, «Борһане тәрәккый», «Вакыт» һәм «Кояш» газеталары текстларында тиешлек формалары реаль чынбарлык һәм тасвирлана торган гамәлнең үзара мөнәсәбәтен бәяләгәндә тиешлек мәгънәсен, төгәлрәк итеп әйткәндә,

мәҗбүрилекне яки катгый кирәклекне белдерү максатында кулланыла. Шул ук вакытта, тиешлек төсмеренә ия теге яки бу тасвирлана торган гамәл семантик дәрәҗәдә һәрвакыт киләчәк заман планына юнәлдерелгән. Күрсәтелгән газета текстларында тиешлек мәгънәсен белдерү берничә синтетик, аналитик һәм тасвирлама грамматик формалар ярдәмендә тормышка ашырыла.

Газета текстларында тиешлекне белдерә торган иң киң таралган формаларның берсе булып *-yrğa* инфинитивы һәм *tiješ* модаль сүзеннән гыйбарәт булган конструкция тора: *...Duma wäkilläre iŋ äwäl bu fidailarnyŋ qotyluy öčen amnistijany* ***trebovat itärgä tiješ*** *wä ğomumi krestianğa aqčasyz cir birelüne* ***trebovat itärgä tiješ*** *dib süzne tämam äjläde* [8]; *Möfti möräcäğat itkän imamlarnyŋ barsyndan da cawablar motlaq waqytynda* ***baryb jetärgä tiješ*** [22]; *...Italija Santiqaranta belän Valonany* ***alyrğa tiješ*** [1].

Еш кына күрсәтелгән конструкциядә *tiješ* модаль сүзе *tiješle* формасында килергә һәм предикатив функциядә кулланылырга мөмкин: *Bolaj ulyr öčen härkem üzeneŋ dusty berlän döšmanyny güzäl tanyb Dumağa da üzeneŋ interesyna čyn küŋeldän köräšüče wäkil* ***sajlarğa tiješle*** [34]; *Din ešlärendä hičber törle qysu wä ämsaly šäjlär* ***bulmasqa tiješleder*** [32]; *Sez bit Zäki abyjyŋ belän ber törle tiplar, sez ber bereŋezne* ***aŋlašyrğa tiješle...*** [13].

«Вакыт» газетасы текстыннан китерелгән мисалдан күренгәнчә, *-yrğa tiješ(le)* тиешлек күрсәткеченең юклык формасы *-masqa tiješ(le)* конструкциясе ярдәмендә ясала.

«Борһане тәрәккый» газетасыннан аермалы буларак, «Вакыт» һәм «Кояш» газеталары текстларында тиешлек мәгънәсе актив рәвештә *-yrğa* инфинитивы, *tiješ* модаль сүзе һәм *ide* ярдәмче фигыленнән гыйбарәт булган *-yrğa tiješ ide* тасвирлама формасы ярдәмендә белдерелә: *...šul säbäble itifaqčylar bu jerlärne ällä qajčan* ***qulğa töserergä tiješ ide*** [19]; *Köndez ike säğatdä kanduktorlar häm vagon jörtüčelär* ***alyšynyrğa tiješ ide*** [31].

«Борһане тәрәккый» газетасы текстларында исә *-yrğa tiješ ide* тиешлек күрсәткече сирәк кулланыла: *Xäqyjqätdä pravitelstva ber partijägä dä qušylmyjča uŋlarğa niček, sullarğa da šulaj uq* ***bulyrğa tiješ ide*** [33].

Моннан тыш, «Вакыт» һәм «Кояш» газеталары текстларында *-yrğa* инфинитивы, *tiješ* модаль сүзе һәм *bul* ярдәмче фигыленнән гыйбарәт *-yrğa tiješ bul* тасвирлама формасының кулланылышы теркәлде: *Üz tupraǧyndan ütkäreb jebärergä... razyj bulmasa any cäberläb tabtab* ***ütärgä tiješ bulyr*** [14]; *Äti doğa qyla bašlady, bez amin* ***totarğa tiješ buldyq*** [36].

«Борһане тәрәккый» газетасы текстларында *-yrğa tiješ bul* формасы урынына, гадәттә, составында *lazem* ‘тиеш, кирәк’ модаль сүзе булган грамматик синонимы *-yrğa lazem bul* тасвирлама формасы кулланыла: *Kamisijä fikerenčä Saratof häm Saritsin rajonlaryndan onny tizräk jebärüne* ***sorarğa lazem buldy*** [27].

Китерелгән мисаллардан күренгәнчә, *-yrğa tiješ bul*/*-yrğa lazem bul* формалары тиешлек мәгънәсен теләсә нинди заман планына күчерү мөмкинлегенә ия, һәм зат кушымчалары турыдан-туры ярдәмче фигыльгә кушылып, зат белән төрләнүнең тулы парадигмасы булу белән аерылып тора. Шуны ассызыклап үтү сорала: бүгенге көндә татар әдәби теле кысаларында иң актив кулланыла торган тиешлек күрсәткечләре булып *-yrğa tiješ ide* һәм *-yrğa tiješ bul* формалары санала [30: 169]. Аларның «Вакыт» һәм «Кояш» газеталары текстларында киң таралышы һәм бераз алдарак чорда чыгып килгән «Борһане тәрәккый» газетасы текстларында азрак кулланылышы XX гасыр башы иске татар язма әдәби теле кысаларында традицион грамматик элементлардан акрынлап баш тарту һәм соңрак яңа татар язма әдәби теле формалашуга нигез булган яңа тел формаларын куллануга күчү белән характерлана торган процессның гамәлдә булуын ассызыклый.

Тикшерелгән газета текстларында тиешлек мәгънәсе шулай ук *-yrğa* инфинитивы һәм *kiräk* модаль сүзеннән гыйбарәт булган грамматик конструкция ярдәмендә дә гамәлгә ашырыла: *Xyjanätne häm kürdeŋez nähar* ***aldanmazğa kiräk*** [21]; *Ufağa baračaq imamlarnyŋ madi cähätlären dä* ***onytmasqa kiräk*** [22]; *Šunlyqdan... ixtyjaclaryna qarab iğanä bilgeläü äsasyn* ***alda totarğa kiräk*** [17].

Мисаллардан күренгәнчә, *-masqa kiräk* тиешлек формасы белән беррәттән текстларда аның *-mazğa kiräk* варианты да кулланыла (*aldanmazğa kiräk*). Әлеге вариант бүгенге көндә угыз телләрендә, аерым алганда, төрек телендә сакланып калган *-maz*/*-mäz* күрсәткече ярдәмендә ясала [23: 227].

«Вакыт» һәм «Кояш» газеталарыннан аермалы буларак, «Борһане тәрәккый» газетасы текстларында, тиешлек мәгънәсен белдерү өчен, бер-берсенә синонимик булган берничә аналитик форманың кулланылуы күзәтелә. Мәсәлән, *-maq* инфинитивы һәм *tiješ* модаль сүзеннән гыйбарәт булган *-maq tiješ* формасы: *Imam äfändelär, mäscedlärdä, xosusa comğa könlärendä cämäğatkä aŋlatyb wäğaz wä näsixät itsä härber möselman jyğlaj jyğlaj järdäm idäčägendä šöbhä juqdyr fäqat* ***aŋlatmaq tiješder*** [15].

Шулай ук, «Борһане тәрәккый» газетасы текстларында *kiräk* модаль сүзе нигезендә ясалган һәм бер-берсенә синонимик булган аналитик формаларның кулланылышы киң таралган. Мәсәлән, шундый конструкцияләрнең бер өлеше *-maq* инфинитивы һәм *kiräk* модаль сүзе кушылмасыннан гыйбарәт: *Min zan idärem ki, ministr xäzrätläre, niček säjäsi yšanyčsyz häm zararly kešelärne jebärgän kebi, Durnovany da Fransijä mämläkätendän* ***jebärmäk kiräk*** [6].

Кайбер очракларда *kiräk* модаль сүзе *-mağa* инфинитивы белән кулланылып, тиешлек мәгънәсен белдерә торган аерым бер аналитик форма тәшкил итәргә мөмкин: *Ämä ber märtäbä ešläb kürgändän soŋ hič qurqyrğa jaramyj, ğajrätle jöräkle* ***ulmağa kiräk*** [21].

Шул ук вакытта «Борһане тәрәккый» газетасы текстларында, тиешлек мәгънәсен белдерү өчен, *-u* исем фигыле һәм *kiräk* модаль

сүзеннән торган *-u kiräk* аналитик формасының кулланылышы теркәлгән: *Jäğni härkem ana telendä uqyb belgänene hičkemdän šiklänmäjenčä jazarğa häm ni teläsä šuny uquğa xörijät* ***bulu kiräk*** [26].

Әлеге газета текстларында тиешлек формаларының бер өлеше *lazem* ‘тиеш, кирәк’ модаль сүзе нигезендә ясала. Мәсәлән, еш кына *-yrğa* инфинитивы һәм *lazem* модаль сүзеннән гыйбарәт булган *-yrğa lazem* формасы очрый: *Qorylğan tormyšlardan razyj bulmağan böten xalyqny üzeneŋ äjlänäsenä cyjyb* ***berläšderergä lazem*** [35].

Аерым текстларда, шулай ук, *-maq* инфинитивы һәм *lazem* модаль сүзе кушылмасыннан торган *-maq lazem* формасының кулланылышы күзәтелә: *Här kemgä mäğlüm ber keše jäki ber milät ber eškä totynsa šul ešneŋ fajdasyn kürmägä* ***čalyšmaq lazemder*** [7].

«Вакыт» газетасы текстларында да, тиешлек мәгънәсен белдерү өчен, *-maq lazem* аналитик формасы сирәк булса да очрый: *Iske tarixymyzğa ğaid ularaq rusča jazylmyš ni qadär äsär var isa cömläsenä* ***tärcemä*** *wä* ***näšer itmäk lazemder*** [4].

Моннан тыш, «Борһане тәрәккый» газетасы текстларында тиешлек мәгънәсе *-u* исем фигыле һәм *lazem* модаль сүзеннән торган *-u lazem* формасы ярдәмендә дә белдерелә: *Xätä miŋa bitläremneŋ bağzy urynlary qara köjgän* ***bulu lazem*** [5].

«Борһане тәрәккый» һәм «Вакыт» газеталары текстларында тиешлек мәгънәсен белдерүнең үзенчәлекле сыйфаты – зат белән төрләнә торган *-maly* формасын куллану. Әлеге форма хәзерге төрек әдәби теленә хас [23: 244], азәрбайҗан, кырым-татар, гагауз һәм чуваш телләрендә очрый [29: 357]. Күрсәтелгән газеталарда *-maly* формасы, гадәттә, XX гасыр башы иске татар язма әдәби теленең угызлашкан вариантында язылган текстларда очрый, аеруча «Борһане тәрәккый» газетасы өчен хас: *Ištä ğolämalyq wä milätkä xedmät bujlä* ***ulmalydyr*** [11]; *Jaurupalylarnyŋ zalimlaryny* ***betermälejez****...* [24].

Китерелгән мисаллардан күренгәнчә, тиешлек мәгънәсенең «Борһане тәрәккый» газетасы текстларында бирелеше бер-берсенә синонимик булган синтетик һәм аналитик формалар ярдәмендә гамәлгә ашырыла. Аларның бер өлеше шул исәптән хәзерге татар әдәби теленә хас соңрак барлыкка килгән лексик-грамматик элементлардан торса, башка формаларның нигезендә исә алдарак кулланылышка кергән гомумтөрки традицион лексик-грамматик элементлар һәм угыз телләре, аерым алганда шул чор төрек әдәби теле өчен хас элементлар ята. «Борһане тәрәккый» газетасында тиешлек мәгънәсен белдерүдәге мондый төрлелек газета теленә һәм XX гасыр башы иске татар язма әдәби теленә традицион тел формаларының һәм госманлы төрек теле аша кергән тел элементларының тәэсире белән аңлатыла. Әлеге төрлелекнең булуы исә тикшерелә торган чорда кулланылышта булган татар язма әдәби теле кысаларында функциональ-стилистик вариантлылыкның гамәлдә булуын дәлилли.

Бу мәкалә кысаларында тикшерелә торган газета текстларының барысында да иң актив кулланыла торган тиешлек формасы булып

*-yrğa tiješ* конструкциясе тора. Югарыда әйтеп үтелгәнчә, шулай ук киң кулланылышта булган *-yrğa kiräk* формасыннан аермалы буларак, ул зат белән төрләнергә мөмкин.

«Борһане тәрәккый», «Вакыт» һәм «Кояш» газеталары текстларында *-yrğa tiješ* тиешлек формасының I һәм II зат берлек санда кулланылу очраклары теркәлмәде. Гадәттә, әлеге форма III зат берлек санда кулланыла. Бу очракта язуда тиешлек мәгънәсен чагылдыру өчен, махсус грамматик күрсәткечләр куллану таләп ителми. Аерым очракларда күрсәтелгән форма *-dyr/-der* хәбәрлек аффиксы белән катлауландырылырга яки аннан башка да кулланылырга мөмкин: *Hindstandağy böten xökümät idarälärendäge xedmätlärgä bezneŋ kerergä xaqymyz* ***bulyrğa tiješder*** [37]; *Bu tädbirne ber Qafqaz xalky ğyna tügel bälki böten Rusijä möselmanlary iğtibarğa* ***alyrğa tiješ*** [20]; *Bu eš tabiğyj, bezgä bik küb jeŋellek, došmanğa bilğakes uŋğajsyzlyq* ***jasarğa tiješder*** [16]; *Üzen šul eškä iqtidarly sanağan xanym wä tutašlar xäzerdänük tübändäge kešelärdä* ***jazyla bašlarğa tiješ*** [18].

III зат күплек санда *-yrğa tiješ* тиешлек формасы шулай ук махсус грамматик күрсәткеч куллануны таләп итми. Бу очракта күрсәтелгән конструкциягә *-lar/-lär* сан кушымчасы һәм, гадәттә, *-dyr/-der* хәбәрлек аффиксы ялгана. Шуны ассызыклап үтәргә кирәк: еш кына хәбәрлек аффиксын күрсәтелгән конструкциягә кушу тәртибе үзгәрергә дә мөмкин. Аерым очракларда *-dyr/-der* күрсәткече турыдан-туры *tiješ* модаль сүзенә кушылып, соңыннан *-lar/-lär* аффиксы килсә, башка очракларда исә башта сан күрсәткече, ә аннан соң хәбәрлек аффиксы кушылырга мөмкин: *Xökümätneŋ daxod wä rasxodlaryny tikšermäk öčen bezgä ixtyjar* ***birergä tiješlärder*** [37]; *Möfti xäzrät tarafyndan Ufağa čaqyrylğan imamlar, bik zur maniğlary bulmağanda motlaq šunda* ***baryrğa tiješderlär*** [22]; *...bolar tarafyndan täqdim itelä torğan kešelär niček kenä iteb bulsa da,* ***ütkärelergä tiješlärder*** [12].

Башка затларда *-yrğa tiješ* формасы сирәк кулланыла. Мәсәлән, газета текстларында әлеге форманың I зат күплек санда кулланылуы теркәлде. Моның өчен *tiješ* модаль сүзенә *-myz/-mez* күрсәткече кушыла: *Xäzer prosent tüläwemez bik üsäčäkne küz aldynda totyb bez mämläkätneŋ iqtisadi wä mali ešlären šuŋa muafiq* ***islax qylyrğa*** *wä* ***xäzerlärgä tiješmez*** [9]; *Šunyŋ öčen bezgä jä ul cyjylyšqa bötenläj qatyšmaj toru, jäki zemstvanyŋ mäğarif öčen täxsis itkän sumasyn praportsijanalnyj bülešü kebek bu oluğ mäsäläne* ***ğaryz itärgä tiješmez*** [2].

Газета текстларында *-yrğa tiješ* тиешлек конструкциясенең II зат күплек сан формасы угыз телләре өчен хас булган [25: 83] һәм кайбер Урта Азия кыпчак телләрендә, аерым алганда казах, каракалпак телләрендә, шулай ук башка фонетик вариантта татар теле диалектларында һәм башкорт әдәби телендә кулланыла торган [10: 183] *-syŋyz/-seŋez* күрсәткече ярдәмендә ясала: *Inde xäzer Rusijäneŋ xörijäten xärbi diktaturanyŋ qara höcümendän* ***saqlarğa... tiješseŋez!*** [3].

Китерелгән мисаллардан күренгәнчә, тикшерелгән газета текстларында тиешлек мәгънәсен белдерү өчен синтетик, аналитик һәм

тасвирлама характердагы синонимик күрсәткечләр һәм конструкцияләр файдаланыла. Семантика күзлегеннән чыгып караганда, алар күпмәгънәле түгел, гадәттә, объектив һәм субъектив факторларга бәйле теге яки бу гамәлне башкаруның мәҗбүрилеге яки кирәклеге мәгънәсен белдерүне максат итеп куя. Шуны ассызыклау сорала: текстларында тиешлек мәгънәсен белдерү өчен билгеле бер сандагы лексик-грамматик күрсәткечләр кулланылган «Вакыт» һәм «Кояш» газеталарыннан аермалы буларак, «Борһане тәрәккый» текстларында әлеге максатларда синонимик характердагы бер төркем күрсәткечләр кулланыла. «Борһане тәрәккый» газетасы текстларында тиешлек мәгънәсен белдерү ысулларының төрлелеге басманың тел үзенчәлекләре, XX гасыр башы иске татар язма әдәби теленең аерым үзенчәлекләре, традицион тел формаларының киң кулланылышы, телгә госманлы төрек теле аша үтеп кергән лексик-грамматик элементларның гомуми йогынтысы кебек факторлар белән бәйле. Әлеге төрлелек тикшерелә торган дәвердә кулланылышта булган татар язма әдәби теле кысаларында функциональ-стилистик вариантлылыкның булуын раслый һәм аның гамәлдәге үзенчәлекләрен күрсәтә.

**Әдәбият**


1. Арнаутлык мәсьәләсенең читенләшүе // Кояш. 1913. № 108.
2. Балкан сугышы мәйданында // Кояш. 1916. № 970.
3. Баш министрның юл хадимнәренә хитабы // Вакыт. 1917. № 2276.
4. Болгар хәрабәләре һәм борынгы болгарлар // Вакыт. 1908. № 333.
5. Борһане тәрәккый. 1906. № 30.
6. Борһане тәрәккый. 1906. № 56.
7. Бу нәрсә бу? // Борһане тәрәккый. 1906. № 29.
8. Вәкилләр озату // Борһане тәрәккый. 1907. № 79.
9. Г. дума җыелышы // Вакыт. 1916. № 1955.
10. *Гаджиева Н.З.* Проблемы тюркской ареальной лингвистики. Среднеазиатский ареал. М.: Наука, 1975. 303 с.
11. Гыйбрәт хәзрәтләр // Борһане тәрәккый. 1906. № 27.
12. Дума сайлауларына даир // Кояш» 1913. № 108.
13. Зәки хәлфәң нишләтте!! // Кояш. 1913. № 50.
14. Инкыйлаф дәүләтләре вә Юнанистан // Вакыт. 1915. № 1768.
15. Инсаниятдан бер хәбәр. Мөселманларга бер нәзер // Борһане тәрәккый. 1906. № 49.
16. Казан 17 март // Кояш. 1915. № 656.
17. Казан хәбәрләре // Кояш. 1914. № 557.
18. Казан хәбәрләре // Кояш. 1917. № 1102.
19. Карадагъ бетү // Вакыт. 1916. № 1955.
20. Карс мөселманлары хәленнән // Вакыт. 1915. № 1752.
21. Киләчәк Дума вә мөселманлар // Борһане тәрәккый. 1906. № 49.
22. Киңәш мәҗлесе алдында // Вакыт. 1913. № 1359.
23. *Кононов А.Н.* Грамматика современного турецкого литературного языка. М., Л.: Изд-во АН СССР, 1956. 569 с.
24. Кытай әхвале // Вакыт. 1912. № 1027.

25. *Негматуллов М.М.* Роль и место огузских элементов в истории развития татарского языка: дис. … канд. филол. наук. Казань: Ин-т яз., лит. и ист. им. Г. Ибрагимова КФАН СССР, 1983. 223 с.

26. Правовой государство // Борһане тәрәккый. 1906. № 32.

27. Русия хәбәрләре // Борһане тәрәккый. 1906. № 29.

*28. Серебренников Б.А., Гаджиева Н.З.* Сравнительно-историческая грамматика тюркских языков. 2-е изд., испр. и доп. М.: Наука, 1986. 301 с.

29. Сравнительно-историческая грамматика тюркских языков. Морфология / отв. ред. Э.Р. Тенишев. М.: Наука, 1988. 557 с.

30. Татар грамматикасы: өч томда. Тулыландырылган 2 нче басма / проект. җит. М.З. Зәкиев. Казан: ТӘһСИ, 2016. Т. II. 432 б.

31. Трамвайда забастовка // Кояш. 1915. № 818.

32. Хаҗи Мөхәммәдов нотыгы // Вакыт. 1909. № 486.

33. Хаҗитархан ноябрь 28 // Борһане тәрәккый. 1906. № 44.

34. Хаҗитархан октябрь 24 // Борһане тәрәккый. 1906. № 37.

35. Хаҗитархан февраль 21 // Борһане тәрәккый. 1907. № 75.

36. Хәкимә абыстай // Кояш. 1914. № 321.

37. Чит мәмләкәт хәбәрләре // Борһане тәрәккый. 1906. № 56.

***Миңнуллин Бәхтияр Ким улы,***
*филология фәннәре докторы, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының гомуми лингвистика бүлеге әйдәп баручы фәнни хезмәткәре, бүлек мөдире*

***Миннуллин Бахтияр Кимович,***
*доктор филологических наук, ведущий научный сотрудник отдела общей лингвистики Института языка, литературы и искусства имени Г. Ибрагимова АН РТ, заведующий отделом*
*bahtiyar1986@yandex.ru*